**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«22» август 2016 ел Круглое Поле авылы № 14

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Круглое Поле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең
2015 елның 8 декабрендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен тормышка ашыру максатрында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 257 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район бюджеты һәм авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына 257 мең сум. |

1.1.«2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

3. Программаны финанслау.

Программаны финанслауның гомуми күләме 257 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финанслар белән идарә итүче-авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе.

Әлеге финанслау күләмнәре тиешле финанс елына бюджетларны формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Низамиева